Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының унөченче утырышы

Питрәч авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

27 май, 2022 ел № 45

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнарга, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2003 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы законнары нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 апрелендәге №128 карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Питрәч авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 өлешне яңа редакциядә бәян итәргә:

«12. Конкурста катнашырга теләк белдергән Россия Федерациясе гражданы конкурс комиссиясенә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) конкурс комиссиясе рәисе исеменә шәхси гариза;

2) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы 667-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә форма буенча кулдан тутырылган һәм имзаланган анкетаны, 4*6 зурлыгындагы төсле фотографияне кушып;

3) паспортының яисә аны алыштыручы документының чын һәм күчермәсен (тиешле документ документлар бергәндә һәм конкурска килгәч шәхсән күрсәтелә);

4) кирәкле һөнәри белем бирүне, эш һәм квалификация стажын раслый торган документлар:

- хезмәт кенәгәсенең билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;

- һөнәри белем турында документларның күчермәләре, шулай ук гражданның теләге буенча - өстәмә һөнәри белем турында, гыйльми дәрәҗә бирү турында,

гыйльми исем бирү турында, нотариаль рәвештә яисә эш (хезмәт) урыны буенча кадрлар хезмәтләре тарафыннан таныкланган документларның күчермәләре;

5) гражданның муниципаль хезмәткә керүгә яисә аны узуга Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен билгеләнгән рәвештә мондый авырулар исемлегендә каралган авыруы булмау турында медицина учреждениесе бәяләмәсе;

6) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ рәвешендә;

7) Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыны буенча салым органында физик затны исәпкә кую турында таныклык;

8) хәрби исәпкә алу документлары - хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле кешеләр һәм затлар өчен.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы Интернет челтәрендәге (www.pestreci.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Питрәч авыл җирлеге башлыгы И.М. Кашапов